

ISSN 0868-4545

Салават күпере

















Көләч хатлар күпләп килә...

Кызык бит, әй!

Соңгы араларда журналханәбезгә хатлар агылып килә башлады. Кайсы гына конвертны ачма, аның эчендә – йә шигырь, йә әкият, йә матур-матур рәсемнәр, йә шаян фотосурәтләр, йә бәйге-конкурсларга килгән мавыктыргыч язмалар, такмак-такмазалар...

Хатларның кинәт кенә шулай ешаюының сәбәбе нидә икән, ә?

Белдек, белдек-төшендек: ямьле яз галәмәте бу! Ягымлы апрель, назлы кояш тәэсиреннән илһамланып, каударланып иҗат итәргә тотынгансыз икән ич сез! Куаныч-шатлыкларыгызны уртаклашасы килү теләге «Салават күпере»нә күпләп-күпләп көләч хатлар юлларга этәргән икән сезне. Шулай бит?!

Апрель аенда дөньяга килгән мәшһүр Тукайның лаеклы алмашлары бит сез: языгыз, куаныгыз, сокланыгыз...

«Салават күпере» нәни Апушлардан янәдән-янә кызыклы, эчтәлекле, мавыктыргыч хатлар көтә.

Йә, кулларыбызга каләмнәр алдыкмы?!



Такмаклар

Бал кортлары очып йөри.
Никтер мине чакмыйлар.
Чәчәк диеп уйлыйлармы?
Мине дә кочаклыйлар.

* * *

Паркка баргач әтием
Атландырды дөягә.
Дөя, мине гел утырт,
Бала-чага төямә.

Алсу ХӘСӘНОВА, 10 яшь.
Әлмәт.

Рәссам Илдар НӘФИЕВ



Дәү әтием минем өчен
Уйлап таба такмакны.
Мин самавыр кайнатырга,
Ваклап торам шакмакны.

* * *

Бик акыллы патшаны һәм
Бер тиле вәзир күрдем.
Әллә төштә, әллә инде
Телевизорда күрдем.

Илмир АХУНОВ, 9 яшь.
Чаллы.



БӘЙГЕНЕҢ КҮҢЕЛЛЕ НӘТИҖӘСЕ

КОНКУРС!

Казан шәһәренең 1000 еллыгына багышлана

«Дию пәрие Казанны алырга килә»

«Салават күпере» журналында без «Дию пәрие Казанны алырга килә» дигән әкияти бәйге игълан иткән идек. Укучыларыбыз әлеге иҗади вә күңелле ярышта бик теләп катнаштылар: журналханәбезгә алардан бик күп, бик күп хатлар килде. Язмалар һаман да килүен дәвам итә. Барысын да журнал битләрендә файдалану мөмкин түгел, әлбәттә. Шуңа да без хатларның иң кызыклы дигәннәрен генә «Салават күпере»нә тәкъдим иттек.

Инде менә бәйгегә йомгак ясарга вакыт та җитте:

I урын – Айгөл ВӘЛИЕВА *(Арча, Яңа Кенәр)*
II урын – Гөлүсә ГАБДРАХМАНОВА (Балтач, Таузар)
III урын – Гөлназ АБЗАЛОВА,
Зөлфинә ГАЗИЗОВА *(Сарман, Җәлил)*.



Җиңүчеләрне котлыйбыз!!!

Хәйләкәр төлке

Дию пәрие барыбер Казанга барырга булган. Өч көн, өч төн җыенган да юлга чыккан. Ул кешеләргә күренмәс өчен урман аша киткән, ди. Бөтен җәнлекләр куркып качканнар. Бары тик хәйләкәр төлке генә курыкмаган.

Төлке:

– Исәнмесез, хөрмәтле Дию пәрие! Кая болай юл тотасыз?

Пәри:

– Кит әле, буталма юлда!



Төлке:

– Зинһар өчен, Дию әфәнде, әйтегез инде!

Пәри:

– Кая булсын, Казанга барам!

Төлке:

– Нишлисез анда?

Пәри:

– Казанны алырга барам.

Төлке:

– Казанны алырга барасызмыни? Курыкмыйсызмы?

Пәри:

– Кемнән? Минме?! Куркам ди хәзер!!!

Төлке:

– Беләсезме, Дию әфәнде, анда милицияләр бик күп. Алар сезне читлеккә ябачаклар бит!

Дию пәриенең гомер эчендә дә милиция сүзен ишеткәне булмаган. Ул аны бик куркыныч нәрсә дип уйлаган, Казанны алу уеннан кире кайткан да өенә элдергән, ди.

Гөлүсә ГАБДРАХМАНОВА, 9 яшь.
Балтач, Таузар.

«Яңа татар» малае

...Дию пәрие җенләнеп торганда, аның янына би-и-ик озын лимузин дигән машина килеп туктаган, ди. Ишеге ачылып киткән, ул ишектән авызына берьюлы өч чупа-чупс капкан, култык астында өч тартма шоколад тоткан малай килеп чыккан, ди. Ул Дию пәриен күреп тә алган, борылып, артындагы мыеклы шоферына боерык та биргән:

– Минем мондый уенчыгым юк иде әле, бу – минеке! Хочу! – дигән.

...Хәзер Дию пәрие әлеге «Яңа татар» малаеның өендә яши, ди. Малай иртәдән кичкә аның өстендә сикергәли, муенына асылынып йөри, юк-бар сорау биреп йөдәтә, ди. Дию абзыйның Казанны җимерү түгел, аягыннан ботинкасын салырга да хәле юк, ди. Кояш баюга, баскан урынында гырылдап йоклап та китә, ди.

Зөлфинә ГАЗИЗОВА, 11 яшь.





Дию шаккаткан

Дию пәрие Казанга барып җиткән. Әйбәтләп кенә Казанны карап чыккан. Бөтен кеше күтәренке күңел белән йөри, ди. Музыка уйный, халык бәйрәмгә әзерләнә. Бу хәлне күргәч, Дию пәриенең тагын да ныграк ачуы килгән. Төрле планнар кора башлаган. Иң башта авызыннан ут чыгарып, Казанны яндырасы килгән аның. Шул вакытта Дию пәриенең бик тә эчәсе килеп киткән. Ул ялтырап яткан Кабан күленә якын килгән. Тәмләп-тәмләп аның салкын суын эчкән. Күл өсте көзге кебек икән. Дию пәрие әлеге көзгедә үзен күреп алган. Күргән дә коты очкан. Бөтен җир матур! Ул Бауман урамы, ул Болак буйлары! Фонтаннардан су бөркелә, яңа йортларның тәрәзәләрендә кояш нурлары ялт-йолт итә. Һәм шунда Дию пәрие... үзенең коточкыч ямьсезлеген аңлап, кинәт кенә юашланган да, шыпырт кына өенә кайтып киткән.

Хәзерге вакытта Казанның туган көненә чакыру җибәргәннәрен көтеп, битенкүзен юып, яңа күлмәк тектереп ята, ди.

Гөлназ АБЗАЛОВА *(яшен күрсәтмәгән)*.



Рәссам Алла АЙСИНА

Журналханәдән:

«Яңа татар» малае» һәм «Дию шаккаткан» дигән язмаларның авторлары З.Газизова һәм Г.Абзалова – Сарман районы Җәлил бистәсендәге 2 нче урта мәктәп укучылары. Икесе дә «Әллүки» иҗат түгәрәгенә (түгәрәк җитәкчесе – Әлфия Илсур кызы Абзалова) йөри икән. Уңышлар телибез аларга!

Журналханәбезгә кызыклы әкияти язмалар юллаган түбәндәге укучыларыбызга да күптин-күп һәм чуктин-чук сәламнәребезне юллыйбыз, рәхмәтләребезне ирештерәбез:

Ләйсән Абдуллина *(Азнакай,Урманай)*,Зифа Миңнегалиева *(Мамадыш)*,Алсу Һадиева *(Арча,Өчиле)*,Ильяс Зарипов *(Кукмара,Янсыбы)*,Ләйсән Гафиятуллина *(Аксубай,Түбән Майна)*,Чулпан Гайфуллина *(Биектау,Өлә)*,Гөлкәй Низамова *(Әлки,Әхмәт)*,Наилә Сабирова *(Казан)*, Алсу Әбүбакирова, Алсинә Бикмуллина *(Яшел Үзән)*, Зөһрә Нигъмәтуллина *(Балтач, Арбаш)*, Алмаз Сәмигуллин *(Апас, Идрәз-Теньки)*, Нурия Садыйкова *(Башкортостан, Аскын, Чураш)*, Илсинә Фәттахова, Ранис Гыймазов,Илдар Исламов *(Актаныш,Иске Солтангол)*,Юлия Әхмәдиева *(Башкортостан,Миякә,Базит)*,Фидарис Ганиев *(Сарман)*,Алсинә Ибраһимова *(Чирмешән,Иске Кади)*,Илназ Насыйбуллин *(Нурлат,Фомкино)*,Ришат Әхмәтшин *(Кама Тамагы,Келәнче)*,Энҗе Дәүләтшина *(Зәй,Югары Лоҗы)*, Дилә Вәлиева *(Чистай, Нарат-Елга)*, Илшат Исмәгыйлев *(Этнә, Әйшияз)*, Айназ Шәвәлиев *(Әлмәт, Яңа Кәшер)*,Инсаф Насыйбуллин *(Саба,Олы Шыңар)*,Ләйлә Кәримова *(Чүпрәле,Иске Задорова)*, Айгөл Әхмәтшина *(Кукмара,Байлангар)*, А.Егомасов *(Чистай,Чув.Ялтан)* һәм башкалар,һ.б.,һ.б.

Иҗади уңышлар сезгә,кадерле дуслар! Сезнең яңа бәйгеләрдә катнашуыгызны көтеп калабыз.

Ләбиб ЛЕРОН

Ике тычкан баласы

Рәссам Фәрит МУЛЛАХМӘТ

Шалтмылтфильм



Кичә-бүген заманда яшәгән, ди, ике тычкан баласы – Тәпи һәм Шәпи.



Беркөнне болар Зәңгәр күлдә балык тотарга уйладылар.



Икесенә ике кармак алдылар да киттеләр Зәңгәр күлгә.



«Балык тотсалар – балыкларын, тотмасалар, үзләрен ашармын!» – дип, болар артыннан кача-поса Актәпи иярде.



«Актәпине эләктерергә җай чыкты!» – дип сөенде Муйнак.



Тычканнар күл буена килеп җиттеләр дә суга кармакларын салдылар.



Шәпи кармагының калкавычы бата-калка башлады.



«Сөен, сөен! Мин эләктергәч нишләрсең микән?» – дип, Муйнак Актәпигә якынлаша башлады.



«Мин ботинка ашамыйм!» – диде дә Актәпи тычкан балаларына ыргылды.



Тычкан балалары, кармакларын ташлап, Актәпигә каршы бастылар.



«Мин монда ялгыш кына килеп эләктем», – дип, Муйнак та тизрәк таю ягын карады.



Шәпинең, балык урынына сыңар ботинка сөйрәп чыгаргач, кәефе төште.



Яшеренгән урыннан чыгып, Муйнак Актәпи артыннан томырылды.



«Ә мин... мин... койма башына үрмәләүче!» – дия-дия, Актәпи артка таба чигенә башлады.



«Бердәмлектә – безнең көч!» – дип, ике тычкан баласы – Тәпи белән Шәпи чичиләп-хихихиләп калдылар.





Вазыйх ФАТЫЙХОВ

Кайда минем оекбашым?

Иртән торсам, оекбаш юк,
Кая киткән, кем алган!
Төнлә кемдер урлашкан,
Киеп каядыр барган?!

Эзлибез бит өй белән,
Хәтта туганнар килгән...
Көтмәгәндә бер тавыш
Аваз бирде бер җирдән.

Актырнак песиебез
«Урлаган» булган икән!
Минем оекбаш өстендә
Бәбие туган икән...

Саран бабай

Әбисе белән Булат
Җиләккә барды берчак.
Пешкән, кызыл җиләкләрне
Ашады учлап-учлап.

– Әбием, – ди, – әбием,
Нигә җиләк баллы? – ди.
Әбисе җавап бирә:
– Бабаң шикәр салды, – ди.

Җыя торгач, кызыллары
Әллә кая югалды.
Булат әллә сизмәдеме –
Яшелен учка алды.

Күзләре шардай ачылды.
Ачылды авыз яман:
– Бабакай боларына
Шикәр салмаган, саран!

Рәссам Светлана ИБРАҺИМОВА

Чәчәкле сөт

Әтиләр печәннәр салыр,
Әниләр сыер савар...
Әлегә бала-чагалар
Сулап йөри саф һава.

Түземсезләнеп балалар
Сыер кайтканны көтә:
Ап-ак, куе, тәмле сөтне
Алар ярата бик тә!

Балалар сорау бирәләр,
Җавап кына уйлап тап:
– Безнең сыер чәчәк ашый,
Нигә аның сөте ак?

– Соравыгыз бик кызыклы,
Тик җавап тапмыйм, балам.
Бу кадәрле зур серләрне
Кояштан сорап кара.

Ул һичшиксез беләдер,
Шуңа серле көләдер.

Лейна ИЛЬЯСОВА

Көтүче Акбай

Акыллы безнең маэмай,
Сөйкемле бик тә Акбай.
Кичке салкын болында
Сыерлар көтә Акбай.

Сыерлар ашап туйгач,
Җиленнәр сөткә тулгач,
Акбай команда бирә,
Өреп ул ара-тирә.

Сөт бик күп җыйгангадыр –
Сыерлар авыр атлый.
Акбай сикергәләп йөри,
Сыерлар санын барлый.

Малкайларын көтеп, хуҗа
Капкасын ачып куя.
Акбай тиз генә малларны
Абзарга ябып куя.








Аделина, 2 яшь 2 ай

– Дәү әниемә булышам
Кунакка килгәндә дә:
Хушбуй исе килеп торсын
Ясалма гөлләрдән дә!

Башкортостан, Миякә.




Илмаз, 2 яшь 11 ай

– Туган көнемә, әйдәгез,
Дуслар, рәхим итегез.
Тәмле суларым беткәнче,
Тизрәк килеп җитегез!

Питрәч.









Конкурс!
Мин бит бу?!



Алия, 5 яшь

– Шундый тәмле аш пешердем –
Әни бигрәк шат инде...
Алло, алло! Әти, синме?!
Әти, тизрәк кайт инде!

Арча, Күпербаш.




Чулпан, 4 яшь

– Йә, кил әле, батыр егет!
Кил инде – җебеп торма...
Батыр егет дип торам ич,
Йә, «җылак җегет» булма!

Кукмара, Югары Шәмәрдән.


Насыйп ризык



Әти безгә гранат алып кайтты. Мин
— Үземнекен алам, дим, ә энем Җәүһәр җылап куйды.
Бер ай узгач кына, иртә белән әти ул гранатны
тапты.

— Бу кемнең гранаты? — дип сорады ул.
— Җәүһәрнеке, — диде әни.
Җәүһәр рөхсәтен сорап, әти гранатны
кисте. Ә ул бозылып каралган иде инде. Әти Җәү-
һәргә болай башка эшләмә, диде. Һәр көн үз ризыгы
белән туа икән ул.

Зыя Фәтхелисламов. 9 яшь.



Җәүһәр ФӘТХЕЛИСЛАМОВ рәсеме.

Татар халкы аш-суга бик оста. Гомер-гомергә пешеренергә–төшеренергә яраткан ул. Туган телебездә аш-суга, ризыкка бәйле гыйбарә, әйтем, мәкальләрнең күп булуы да бик табигый. Берничәсен мисал итеп китерәбез.

– Насыйп ризык теш сындырып керә.

– Аштан олы булма.

– Аз кап, май кап.

– Эше барның ашы бар.

– Кунак ашы – кара-каршы.

Зыя Фәтхелисламов та үзенең хатында «Һәр көн үз ризыгы белән туа» дигән матур нәтиҗәгә килгән. Бездә әле тагын «Һәркем үз ризыгы белән туа» дип тә әйтәләр.

Кадерле дускай!

Аш-су, табын турында гыйбарә-мәкальләрне, бәлки, үзең дә беләсеңдер. Белмәсәң, әтиеңнән-әниеңнән, әбиеңнән-бабаңнан сора һәм безгә язып җибәр. Бу беренче бирем. Икенче бирем – «Таш атканга аш ат» дигән гыйбарәнең мәгънәсе нидән гыйбарәт? Шуны аңлат. Бәлки, шушы сүзләрне кертеп, безгә хикәя, әкият язып җибәрерсең.





Ркаил ЗӘЙДУЛЛА

Маймыч

Әнисе Маймычны мәктәпкә җибәрде: «Тәртипле йөр, әйбәт укы», – диде.

Маймычның мәктәпкә барасы килми иде. Су җылы, әллә кайдагы кояшның җылы нурлары күл төбенә төшеп әбәкле уйный. Маймыч, мәктәпкә китмичә, яр буена якынлашты. Монда күңеллерәк сыман иде. Авыз суын китереп, симез суалчаннар эленеп тора.

Шул арада кайдандыр ак мыеклы Табан бабай килеп чыкты. «Бу тирәдә йөрмә, Маймыч! – диде ул иреннәрен бөрештереп. – Әнә күрәсеңме суалчаннарны?» Күрмәскә, Маймыч сукыр түгел лә... «Алар кармакка кидерелгән... – Табан бабай күзлеген рәтләп куйды. – Кабуың була, ялтырап яр өстенә килеп тә төшәсең... Матри!»

Маймычның үтереп суалчан ашыйсы килә башлады. Җайлап кына аны кармактан суырып чыгарсаң, ә?

Маймыч суалчанны кабуы булды, яр өстенә килеп тә төште. Бер малай аны учына алды. «Һи, бигрәк кечкенә нәстә эләккән», – диде ул. Аннары Маймычка төкерде дә кире күлгә ыргытты.

Ай-яй-яй! Күл төбендә генә аңга килде Маймыч. Анда инде бүтән балыклар да җыелган иде. Әнисе дә килеп җиткән. Маймычның маңгаена берне кундырыйм, дип Табан бабай койрыгын күтәргән иде дә, кызганды бугай, кире төшерде.

– Исегез киткән! – дип кычкырды Маймыч. – Кармактан куркасыз. Ә мин дөнья күрдем. Анда бер малай белән күрештек. «Сәлам, Маймыч энекәш!» – диде.

– Маймыч дөнья күргән! – дип шаккатты балыклар.

– Ә сез күл төбендә томана булып ятасыз! – дип күкрәк киерде Маймыч. – Бераз үскәч, мине теге малай Казанга алып китәчәк. Анда урысча өйрәнермен, Сезнең белән тел әрәм итеп сөйләшеп тә тормам.

– Ай-яй-яй! – диештеләр нәни балыклар.

Шул көннән соң Маймыч тәмам ирәйде. Иртән тешен дә чистартмый башлады. Хәтта юынырга да теләмәде. Мәктәпкә дә бармады.

– Нигә миңа мәктәп? – диде ул әнисенә. – Надан балыклар миңа нәрсә өйрәтә ала?

Ләмгә батып тик рәхәт чигеп ята хәзер Маймыч. Юк ла, хәзер Маймыч та түгел, көн буе суга төкереп ята торгач, симерде, зурайды. Гәүдәсен чак селкетеп йөри.

Рәхәтен рәхәт, тик күңелсез шул. Дөнья күрәсе килә. Ул янә суалчаннар янына юнәлде. Бер суалчанны кабуы булды, ялтырап яр өстенә килеп тә төште.

– Һо! – дип шатланды малай. – Нинди симез балык эләкте! Үзе бер табалык! – Һәм ул аны киндер капчыкка салып, Казанга алып китте.



Рәссам Илдар НӘФИЕВ







Безнең урам

Безнең урам – зур урам,
Мин шул урамда торам.
Тирә-якта күршеләр,
Бар да уңган кешеләр.
Рәзинә апа – сатучы,
Фәния апа – бакчачы.
Илгизәр абый йорт сала,
Зиннур абый түбә яба.
Суфия апа укыта,
Инсаф абый балык тота.
Габдулла абый – тимерче,
Миңлегөл апа – тегүче.
Рафак абый – командир,
Рамил абый – бригадир.
Гаяз абый – шофёр,
Ринат абый – монтёр,
Линар абый – көтүче,
Ә мин – ярдәм итүче!

Ләйсән БАТЫРОВА, 9 яшь.
Кукмара, Чишмәбаш.



Динар НИЗАМОВ, 11 яшь. *Кайбыч, Зур Русак.*



Ләйсән ӘХМӘТОВА, 9 яшь. *Татарстан.*



Ранил НИЗАМОВ, 6 яшь. *Кайбыч, Зур Русак.*



Эльвира БАТЫРШИНА, 9 яшь.
Тукай, Ташкичү.

Көрәк

(Әкият)

Яшәгән ди, булган ди бер абзый һәм аның көрәге. Менә бер көнне абзый әйткән: «Көрәк, бар, бакчага чык!» – дигән. Көрәк чыкмаган. Шул көнне абзый күрә: бакчада бәрәңге утыртылмаган. Абзый бик каты көрәкне ачуланган ди. Көрәк өеннән качкан. Бөтен кеше бакчага чыккан ди. Абзый җиргә утырып, җылап җибәргән ди. Бер көнне абзый кибеткә барган чакта каршысына көрәк килеп чыккан ди. Абзый әйтә икән:

– Көрәгем, өйгә кайт инде!

– Ярар, – дигән көрәк, – әгәр мине тагын ачулансаң, мин бер кайчан да кайтмыйм!

Шул көннән соң алар бик тату яшәгәннәр ди.

Хәйдәр КАЮМОВ, 9 яшь.
Саба, Лесхоз.



Гөлназ ВӘЛИУЛЛИНА, 7 яшь.
Чүпрәле, Иске Кәкерле.



Айгиз КАШАПОВ, 7 яшь. *Мөслим.*

Хәтерлим мин әле...

«Уртасына!»

Беренче сыйныфта укый идек. Укытучыбыз аңлата: «Балалар, төсле кәгазьне әрәм итмәү өчен без үрнәкне аның иң читенә куеп төшерербез», – ди.

Алдагы дәрестә укытучыбыз сорый: «Төсле кәгазьне әрәм итмәү өчен без үрнәкне аның кайсы урынына куеп төшерәбез әле?»


Миннән кала, сыйныфташларым берсен-берсе уза-уза: «Уртасына, уртасына?» – дип кычкырырга тотындылар.

Алсу ЗӨБӘЕРОВА, 10 яшь.
Арча, Зур Бирәзә.




Сканворд

Тукай һәм яз



Төзеде Гүзәл СӘЕТОВА

Ребус



Рәссам Фәрит МУЛЛАХМӘТ

Игътибар!

Татарстан Мәгариф министрлыгы, Татарстан Язучылар берлеге, «Мәгариф» һәм «Салават күпере» журналлары яңа бәйге игълан итә.

«Салават күпере» журналын файдаланып, дәреснең яисә тәрбия сәгатенең (башлангыч сыйныфлар өчен) тулы план-конспектын язарга кирәк.

Уңышлы дип саналган план-конспектларны аерым җыентык итеп чыгару күздә тотыла.

I урын өчен – 5000 сум.

II урын өчен – 3000 сум.

III урын өчен – 2000 сум.

Конкурска йомгак 2005 елның гыйнвар аенда ясалачак!

Белешмәләр өчен телефоннар:

36-00-81,

36-30-01.

Жюри.

Тышлыкның беренче битендә кулланылган рәсемнәрнең авторлары:

Чулпан ӘХӘТОВА (7 яшь, *Саба, Эзмә*), Ришат ГАНИЕВ (8 яшь, *Тукай, Биклән*), Ирек ХӘБИБУЛЛИН (9 яшь, *Лениногорск*), Ризәлә САФИНА (9 яшь, *Арча, Яңасала*), Илназ ГӘРӘЕВ (6 яшь, *Арча, Иске Кишет*), Рүзинә ГАРИФУЛЛИНА (9 яшь, *Спас, Рәҗәп*), Алисә САДЫЙКОВА (9 яшь, *Балтач, Югары Шубан*).

Салават күпере

4(169) — 2004

ЖУРНАЛНЫ ГАМӘЛГӘ КУЮЧЫ: ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЖИР, МИЛЕК МӨНӘСӘБӘТЛӘРЕ МИНИСТРЛЫГЫ, ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАР БЕРЛЕГЕ ИДАРӘСЕ ҺӘМ РЕДАКЦИЯ КОЛЛЕКТИВЫ.

1990 елның март аеннан бирле чыга.

УЧРЕДИТЕЛИ: МИНИСТЕРСТВО ЗЕМЕЛЬНЫХ И ИМУЩЕСТВЕННЫХ ОТНОШЕНИЙ РТ, ПРАВЛЕНИЕ СОЮЗА ПИСАТЕЛЕЙ РТ И КОЛЛЕКТИВ РЕДАКЦИИ.

Основан в 1990 году.

На татарском языке.

Татарстан Республикасы Мәгълүмат һәм матбугат министрлыгы тарафыннан 96 нчы номер белән теркәлде.

Баш мөхәррир
Зиннур ХӨСНИЯР

Баш мөхәррир урынбасары
Вакыйф НУРИЕВ

Җаваплы сәркатип
Ләбиб ЛЕРОН

Бизәлеш мөхәррире
Фәрит МУЛЛАХМӘТ

Компьютер дизайны
Фидель ХӘСӘНОВ

Исәп-хисап бүлеге
Рәмзия САЛИХ

Тышлыкта Фәрит МУЛЛАХМӘТ, Фидель ХӘСӘНОВ һәм Алла АЙСИНА коллажы.

Мәктәпкәчә яшьтәге һәм кече яшьтәге мәктәп балалары өчен.

Адрес редакции:
420012 г. Казань, ул. Муштари, 14.
E-mail: ck-sxn@newmail.ru

«Салават күпере» журналының компьютер үзәгендә җыелды һәм тәсләргә бүленде.

«Идел-пресс» полиграфия нәшрият комплексы» дәүләт унитар предприятиясе.

Казан, Декабристлар урамы, 2 нче йорт.

Производствога бирелде 08.04.2004 ел.
Басарга кул куелды 08.04.2004 ел.
Кәгазь форматы 60х100 1/8.
Гарнитура – Прагматика.
Офсет ысулы белән басылды.
Тиражы 12801 данә. Заказ Э-230.

Бәясе килешү буенча
Индекс 73953

ХӨРМӘТЛЕ ӘТИ-ӘНИЛӘР!

Сабыйларыгызны куандырырга теләсәгез, «Салават күпере» журналына 2004 елның икенче яртысына язылырга онытмагыз.

Журналның индексы – 73953.

Бәясе – ярты елга 60 сум.

КЕШЕ БУЛАСЫМ КИЛӘ...

ХӘЗЕРГЕ ТАТАР АЛФАВИТЫ

А а	И и	Р р	Ш ш
Ә ә	Й й	С с	Щ щ
Б б	К к	Т т	ъ
В в	Л л	У у	Ы ы
Г г	М м	Ү ү	ь
Д д	Н н	Ф ф	Э э
Е е(ё)	Ң ң	Х х	Ю ю
Ж ж	О о	Һ һ	Я я
Җ җ	Ө ө	Ц ц	
З з	П п	Ч ч	

ЛАТИН АЛФАВИТЫ

A a	H h	O o	W w
Ə ə	I ı	Ɵ ɵ	X x
B b	İ i	P p	Y y
C c	J j	R r	Z z
Ç ç	K k	S s	
D d	Q q	Ş ş	
E e	L l	T t	
F f	M m	U u	
G g	N n	Ü ü	
Ğ ğ	Ņ ņ	V v	

ГӘРӘП АЛФАВИТЫ

"Татмедиа" массакүләм коммуникация агентлыгы. Индексы 73953. Редакциянең адресы: Казан, Мөштәри ур., 14.
Тел. (8432) 36-00-81, Факс (8432) 36-72-42, e-mail: ck-sxn@newmail.ru